**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге башлыгы карары**

**2023 елның 14 ноябре** **№ 7**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Поршур авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1 2023 елның 28 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Поршур авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кече Чура авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча Кече Чура авылы клубы бинасында үткәрергә.

2 2023 елның 28 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Поршур авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кече Чура авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча Кече Чура авылы клубы бинасында үткәрергә.

3 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлегенең Поршур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Поршур авылының урамына, тыкрыгына юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Поршур авылына урам яктырту лампалары сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;

- Поршур авылына насослар сатып алу һәм артезиан скважиналарын, су башняларын, су саклау зоналарын, су белән тәэмин итү системаларын карап тоту;
- Поршур авылында чишмәне төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Поршур авылында автомобиль юлын (переход) ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Поршур авылының урам юл челтәрен карап тоту; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эш өчен түләү, тракторчы-машинист хезмәте күрсәтү;
- Поршур авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү;
- Поршур авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисеп ташлау, кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Поршур авылында су башнялары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;
- Поршур авылында юлларга асфальт салу һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Поршур авылына балалар һәм спорт мәйданчыкларын һәм якын-тирә территорияләрне яктырту; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы: В.Н. Андреев